РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТИХОНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423655 Менделеевский район, с. Тихоново, ул. Шишкина д. 3А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТИХОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423655 Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин урамы, 3А

тел./факс (85549)3-43-62 Email: Tihon.Men@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

11 декабрь 2024 года № 24

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районының Тихоново авыл
җирлегендә бюджет процессы
турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмә"гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«3. Бюджет керемнәре администраторы түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

1.бюджетка түләүләрне, пеняларны һәм штрафларны башкаруның тулысынча һәм үз вакытында башкарылуын исәпләп чыгаруны, исәпкә алуны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

2.бюджетка түләүләр буенча бурыч, пенялар һәм штрафлар түләтүне гамәлгә ашыра;

3.бюджетка артык түләнгән (түләтелгән) түләүләрне, пеняларны һәм штрафларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык түләтелгән суммага исәпләнгән процентларны кире кайтару турында карар кабул итә һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен Федераль казначылык органына йөкләмә тапшыра;

4.Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләрне исәпләү (төгәлләштерү) турында карар кабул итә һәм Федераль казначылык органына хәбәрнамә тапшыра;

5.бюджет керемнәренең баш администраторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бюджет керемнәренең баш администраторына бюджет керемнәренең тиешле баш администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне һәм бюджет хисаплылыгын төзи һәм тапшыра;

6. физик һәм юридик затларның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен акчаларын түләү өчен кирәкле мәгълүматны түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча бирә, шулай ук дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт Мәгълүмат Системасына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-

ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына кертә, моңа Россия Федерациясе законнарында каралган очраклар керми;
7.бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итә;
8.бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә әзерләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели:
9. Россия Федерациясенең бюджет законнарында һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актларда, шулай ук әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.»
1.2. 19 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
3) “Туристлык салымы - норматив буенча 100 процент”;
2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасы нигезләмәләре Менделеевск муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына (2025 елга) бюджетлардан башлап кулланыла.
3. Әлеге карарны махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Тихоново авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Тихоново авыл җирлеге Советы рәисе А.М. Карманов